**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**04.09.2019** **№1486**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында гаилә мәгарифе һәм үзбелем алу турында Нигезләмәне раслау турында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында”, 2012 елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының “Гаилә формасында белем алуны оештыру турында”, 2013 елның 15 нче ноябрендәге НТ-1139/08 номерлы хаты, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының “Гаилә мәгарифе һәм үз белем алу формасында белем алуны оештыру турында”, 2018 елның 29 нче ноябрендәге РК-5/18 номерлы хаты нигезендә, Россия Федерациясе гражданнарының гомуми белем алу формасына хокукларын тәэмин итү максатыннан, Биектау мунииципль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гаилә мәгарифе һәм үзбелем алу формасында гомуми белем алу турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы 2 номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбен” МБББУсен гражданнар гаилә мәгарифе яки үзбелем алу формасында белем алырга мөмкин булган учреждение дип санарга.
3. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы 2 номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе” МБББУсе җитәкчесенә (Абдрахманов Ф.Ф.) экстерннарның арадагы йомгаклау аттестацияләрен уздыруда җәлеп ителгән педагогик хезмәткәрлрнең хезмәтенә түләүне оештырырга.
4. Форманы расларга:

- гаилә мәгарифе формасында яки үзбелем алу формасында белем алу формасын сайлау турында хәбәрнамә (2 нче кушымта);
- гражданинның яки аның әти-әнисенең (законлы вәкилләренең) мәгариф оешмасына арадагы һәм/яки дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн белән узу өчен кабул ителүгә гаризасы (3 нче кушымта) ;
- экстернны кабул итү турында боерык формасы (4 нче кушымта);
- гомуми белем бирү оешмасында арадагы аттестация узу һәм гаилә мәгарифе яки үзбелем алу формасында белем алучы балаларның исәп китабы формасы турында белешмәләр (5 нче кушымта);
- гомуми белемне гаилә мәгарифе яки үзбелем алу формасында белем алучы укучының арадагы һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм уздыру турында шартнамәләр (6 нчы кушымта);
- белемне гаилә мәгарифе формасында яки үзбелем алу формасында белем

алучы балаларның исәп журналын алып бару (7 нче кушымта).

5. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – мәгариф бүлеге начальнигы Әхмәтҗанов Н.К.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта

«РАСЛАНГАН»

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
04.09.2019 №1486

Биектау муниципаль районында гаилә мәгарифе һәм үзбелем алу фармаларында гомуми белем алу турында нигезләмә

## I.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә РФ һәм ТР Конституцияләре, РФ һәм ТР Гаилә кодекслары, “Россия Федерациясендә мәгариф турында”, 2012 елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, “Мәгариф турында”, 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының “Гаилә формасында белем алуны оештыру турында”, 2013 елның 15 нче ноябрендәге НТ-1139/08 номерлы хаты, башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләп чыгарылган.

1.2. “Россия Федерациясендә мәгариф турында”, 2012 елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гомуми белемны алырга мөмкин:

а) белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмаларда;

б) белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалардан тыш (гаилә мәгарифе һәм үзбелем алу формаларында).

1.3. Укучыларның ихтыяҗларын һәм шәхси мөмкинлекләрен истә тотып, гомуми белем бирү программалары гаилә мәгарифе һәм үзбелем алу формаларында үзләштерелергә мөмкин. Гаилә мәгарифе һәм үзбелем алу формасында укыту мәгариф эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмаларда алга таба арадагы һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен узу хокукы белән тормышка ашырыла.

1.4. Гаилә мәгарифе эти-әниләр (закон вәкилләр) инициативасы буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми гомуми белем бирү программалары буенча мәгариф учреждениеләреннән тыш, гаиләдә бала тарафыннан үзләштерү формасы.

1.5. Үзбелем алу укыту формасы буларак аерым фәннәр, сыйныфлар, урта гомуми белем курслары буенча гомуми белем бирү программаларын алга таба аккредитация узган мәгариф оешмаларында аттестация узып үзлектән, тизләштерелгән өйрәнүне күз алдында тота.

1.6. Гаилә формасында яки үзбелем алу формасында белем алучы зат, үзенең яки эти-әниләренең (законлы вәкилләрнең) карары буенча балигъ булмаган укучының фикерен дә исәпкә алып, укытының теләсә кайсы этабында аны, Закон белән күздә тотылган башка төрле формада дәвам итә ала, яисә мәгариф һәм укытуның формаларын берләштерергә хокуклы.

1.7. Гомуми белем бирүгә хокукы булган балаларның исәбен алып баруны, бала яшәүче территориядә урнашкан “ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге” МКУсе (алга таба – Мәгариф бүлеге) алып бара.

1.8. Балигъ булган укучы яки балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) укучы яшәүче территориядә урнашкан район мәгариф бүлегенә гаилә мәгарифе/үзбелем алу формасында гомуми белем алу формасын сайлау турында 2 нче кушымта нигезендә хәбәрнамә җибәреп мәгълүмат җиткерә.

1.9. Район мәгариф бүлеге белем алуның гаилә мәгарифе формасын яки үзбелем алу формасын сайлаган укучы турында мәгълүматны, укытылырга тиешле һәм мәгариф оешмаларында укымый торган балалар реестрына кертүне тәэмин итә. Гаилә мәгарифе/ үзбелем алу формасы буенча белем алуны сайлаган, ләкин мәгариф оешмаларына экстерн сыйфатында теркәлмәгән укучыла, мәктәп укучыларының бөтенроссия олимпиадаларында, күргәзмәләрдә, смотрларда, физик культура чараларында, спорт чараларында гариза бирү тәртибендә катнашырга хокуклы. Бу очракта чарада катнашу өчен гариза укучы яшәүче территориядә урнашкан район мәгариф бүлегенә бирелә.

1.10. Укучы яшәүче территориядәге район мәгариф бүлеге гаилә мәгарифе/үзбелем алу формасында белем алу турында мәгълүматны алганнан соң, балигъ булган укучыны яки балигъ булмаган укучының әти-әнисен (законлы вәкилләрен) укучы арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узарга мөмкин булган районның мәгариф оешмасы турында мәгълүмат җиткерә.

1.11. Мәгариф бүлеге мәгариф оешмасын арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен укучының мәгариф оешмасына беркетелүе турында (анда буш урыннар булган очракта) мәгълүматлар җиткерә.

1.12. Балигъ булган укучы яки балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу турында гаризаны (3 нче кушымта) белем алуның гаилә мәгарифе формасын яки үзбелем алу формасын сайлау белән бәйле рәвештә мәгариф оешмасыннан чыгарылу турында гариза белән бер үк вакытта бирергә хокуклы.

1.13. Гариза белән бергә түбәндәге документлар биреләләр:

- балигъ булган гражданинның шәхесен ачыклаучы документның төп нөсхәсе;
- балигъ булмаган гражданинның әти-әнисенең (законлы вәкиленең) шәхесен ачыклаучы документның төп нөсхәсе;
- баланың туу турында таныклыгының төп нөсхәсе, яисә билгеләнгән тәртиптә, гариза бирүченең туганлыгын раслаучы документның күчермәсе (яки балигъ булмаган экстерн өчен хокуклар бирү законлылыгы);
- шәхси эш (мәгариф учреждениесендә шәхси эш булмаган очракта, аттестация узу вакытында шәхси эш рәсмиләштерелә);
- гомуми белем бирү программаларын үзләштерүне раслаучы (алар булган очракта) документлар (төп башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне тормышка ашыручы гомумибелем бирү мәгариф учреждениесендә уку турында белешмә, мәгариф учреждениесендә арадагы аттестация турында белешмә, төп гомуми белем турында документ).

1.14. Район мәгариф бүлеге әти-әниләр тарафыннан, балигъ булмаганнарның гомуми белем алу өлкәсендә йөкләмәләрен тотуга контроль уздыру максатыннан, балигъ булмаганнар Комиссиясенә барлык түбәндәге очраклар турында хәбәр итә:

- мәгариф оешмасыннан гаилә мәгарифе яки үзбелем алу формасын сайлау белән бәйле рәвештә китү һәм балигъ булганның яки балигъ булмаганның әти-әнисенең

(законлы вәкиленең) арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясе өчен мәгариф оешмасына беркетелүе турында мәгълүматлар бирүдән баш тарту;
- арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясе узу өчен билгеләнгән вакытта экстернның килмәве.

1.16. Арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен мәгариф учреждениесенә теркәлгән затлар экстерн булып аталалар. Экстерннар укучылар булып торалар һәм укучыларга бирелә торган барлык академик хокукларга ия. Экстерннар кирәк булган очракта, социаль-педагогик һәм психологик ярдәм, түләүсез психолого-медик-педагогик коррекция алуга өмет итә ала.

1.17. Мәгариф оешмасы экстернга түләүсез куллануга арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу вакытына, мәгариф учреждениесе җитәкчесе тарафыннан расланган фәннәрне укытуны тәэмин итүче уку әсбаблары һәм уку ярдәмлекләре исемлеге нигезендә, уку әсбаблары, уку ярдәмлекләре тәкъдим итә.

## 2. Укучы тарафыннан гаилә мәгарифе/үзбелем алу формасында белем алу формасын сайлаганда белем бирү мөнәсәбәтләре килеп туу

2.1. Балигъ булган укучы яки балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) мәгариф учреждениесенә беелм алуның гаилә формасын яки үзбелем алу формасын сайлау белән бәйле рәвештә укучыны чыгару турында гариза белән мөрҗәгать итәләр. Күрсәтелгән гариза нигезендә, мәгариф оешмасы өч эш көне эчендә укучыны чыгару турында боеру акты чыгара.

2.2. Мәгариф оешмасы балигъ булган укучыга яки балигъ булмаган укучының әти-әнисенә (законлы вәкилләренә) укучының шәхси эшен һәм мәгариф оешмасының мөһере һәм оешманың җитәкечесе имзасы белән расланган, агымдагы уку елында укучының өлгергәнлеге турында мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшыра.

2.3. Мәгариф мөнәсәбәтләре килеп тууга нигез булып, мәгариф оешмасының арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу турында боеру акты тора.

Арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен гражданнарны кабул итү балигъ булган укучының яки балигъ булмаган укучының әти-әнисенең (законлы вәкилләренең) шәхси гаризасы буенча тормышка ашырыла. Экстернны мәгариф оешмасына кабул итү, гаризада күрсәтлегән вакытта тоомышка ашырыла, мәгариф оешмасының боеру акты белән (4 нче кушымта) документларны кабул иткәннән соң 7 эш көне дәвамында рәсмиләштерелә. Гаризада һәм боеру актында күрсәтелгән вакыт беткәннән соң, экстерн мәгариф оешмасыннан чыгарыла.

2.4. Экстерн тарафыннан арадагы аттестация узу турында гариза бирү срогы, шулай ук арадагы аттестация узу формасы мәгариф оешмасы тарафыннан билгеләнелә.

Урта гомуми белем бирү программасы буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен экстерн тарафыннан гариза бирү срогы 1 февральдән дә соңга калырга тиеш түгел, төп гомуми белем бирү программасы буенча 1 нче марттан да соңрак була алмый алмый.

2.5. Укучының мәгариф учреждениесенә арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен экстерн буларак теркәлүе, гражданнарны мәгариф

оешмаларына кабул итү өчен гамәлдәге законнар (Мәгариф һәм фән министрлыгының “Гражданнарны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укытуга кабул итү Тәртибен раслау турында”, 2014 ел, 22 нче гыйнвар, 32 номерлы боерыгы) нигезендә билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла.

2.6. Мәгариф оешмасы гражданинны кабул итүдән анда буш урыннар булмаган очракта гына кире кага ала. Мәгариф оешмасында буш урыннар булмаган очракта, балигъ булган укучы яки балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) аны башка мәгариф оешмасына урнаштыру турында мәсъәлә буенча районның мәагриф бүлегенә мөрәҗәгать итәләр.

2.7. Экстернның шәхси эше булмаган очракта, аралагы һәм (яки) дәүләт (йомгаклау) аттестациясен узу вакытына мәгариф оешмасында шәхси эш ачыла.

## 3. Экстерннарның арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм уздыру

3.1. Үзбелем алу яки гаилә мәгарифе формасында төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче затлар, экстерн буларак арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен, дәүләт аккредитациясе булган билгеле белем бирү программасы буенча белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыра торган оешмада узарга хокуклы.

Төп яки урта гомуми белеме булмаган күрсәтелгән затлар, экстерн буларак аралагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен, дәүләт аккредитациясе булган билгеле белем бирү программасы буенча белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыра торган оешмада түләүсез узарга хокуклы.

3.2. Мәгариф оешмасы тарафыннан, арадагы аттестацияне оештыру һәм үтүне регламентлаучы, шул исәптән экстерннар тарафыннан билгеле локаль акт кабул ителергә тиеш. Күрсәтелгән локаль актта экстерн тарафыннан гариза бирү срокларын, экстернның арадагы аттестация уздыру срокларын, экстернның арадагы аттестация уздыру формалары һәм тәртибе, шулай ук консультацияләр уздырган вакытта дистанцион мәгариф технологияләрен куллану мөмкинлеге күрсәтелергә тиеш.

Мәгариф оешмасы экстернның гаризасына арадагы аттестация уздыруның шәхси срокларын билгеләргә, үзләштерелә торган мәгариф программасы кысаларында тизләтелгән укыту мөмкинлеген күз алдында тотарга тиеш.

Арадагы аттестация уздыру формасы һәм тәртибе мәгариф оешмасының локаль акты белән билгеләнелә, шулай ук гаилә мәгарифе яки үзбелем алу формасында урта белем алучы укучының арадагы һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм уздыру турында шартнамә төзелә (7 нче кушымта).

3.3. Гаилә мәгарифе/үзбелем алу формасында урта белем алганда мәгариф оешмасы бары тик оешма һәм арадагы һәм (яки) дәхләт йомгаклау аттестация уздыру, шулай ук укучының билгеле академик хокукларын тәэмин итү өчен генә җаваплылык тота.

Әти-әниләр (законлы вәкилләр) белемнәр, сәләтләр, күнекмәләр һәм компетенция, эшчәнлек тәҗрибәсе алу, сәләтләрне үстерү, көндәлек тормышта

белемнәрне куллану тәҗрибәсен туплау һәм укучыда гомере буе белем алуга мотивация булдыру буенча укучының максатчан юнәлешле эшчәнлеге өчен җаваплылык тоталар.

Урта гомуми һәм төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен узу мәҗбүри булганлыктан, экстернның әти-әниләре (законлы вәкилләре) укучы тарафыннан аны үтү өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылык тоталар.

3.4. Мәгариф оешмасы аттестациясен узу тәртибе балигъ булган укучының яки балигъ булмаган укучының әти-әнисе нең(законлы вәкилләренең) фикерләрен истә тотып, шул исәптән уку материалын өйрәнү темпларыннан һәм эзлеклелегеннән чыгып билгеләнергә тиеш.

3.5. Белем бирү программасының бер яки берничә уку предметлары, курслары, дисциплиналары (модульләре) буенча арадагы аттестациянең канәгатьләнедерерлек булмаган нәтиҗәләре яки арадагы аттестацияне, хөрмәткә лаек сәбәпләрсез мәгариф оешмасы боеру акты белән билгеләнгән срокларда узмау, академик бурыч дип таныла.

Балигъ булмаган экстернның әти-әниләре (законлы вәкилләре) һәм мәгариф оешмалары академик бурычны бетерү өчен шартлар тудырырга һәм аны вакытында бетерүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә тиеш.

3.6. Академик бурычлары булган экстерннар билгеле фән предметы, курс, дисциплина (модуль) буенча арадагы аттестацияне, академик бурыч килеп туган моменттан бер ел эчендә мәгариф оешмасы белән билгеләнгән срокларда ике тапкырдан артмаган күләмдә узарга хокуклы. Күрсәтелгән вакытка экстернның авырган, акдемик ялда булган яки йөклелек һәм бала табу буенча түләүле ялда булган вакыт кертелми.

Арадагы аттестацияне икенче тапкыр уздыру өчен мәгариф оешмасы тарафыннан комиссия төзелә.

3.7. Экстерннарның арадагы аттестацияне тапшыру турында нәтиҗәләре беркетмәләрдә күрсәтеләләр.

3.8. Дәүләт йомгаклау аттестациясен узмаган яки дәүләт йомгаклау аттестациясендә канәгатьләндерелмәслек нәтиҗәләр алган экстерннар дәүләт йомгаклау аттестациясен, билгеле белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестацияссен уздыру тәртибе белән билгеләнелә торган срокларда узарга хокуклы.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен узмаган затларга яки дәүләт йомгаклау аттестациясендә канәгатьләндерелмәслек нәтиҗәләр алган экстерннарга, ирекле формада мәгариф оешмасы белән билгеләнән торган уку турында яки уку чоры турында белешмә бирелә.

3.9. Арадагы аттестацияне йзган һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен уза алмаган экстерннарга, арадагы аттестация турында 6 нчы кушымта нигезендә белешмә бирелә.

3.10. Дәүләт йомгаклау аттестациясен узган экстерннарга дәүләт йомгаклау аттестациясе уздырылган мәгариф оешмасы тарафыннан төп урта яки урта гомуми белем турында документ бирелә.

3.11. Гаилә мәгарифе формасында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта

гомуми белем бирү программалары буенча билгеләнгән срокларда академик бурычларын бетермәгән укучылар мәгариф оешмасында белем алуларын дәвам итәләр.

## 4. Гаилә мәгарифе/үзбелем алу формасында белем алучы укучыларга арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм уздыруны финанс тәэмин итү

4.1. Гаилә мәгарифе/үзбелем алу формасында белем алучы укучыларга арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм уздыруны финанс тәэмин итү, агымдагы финанслау кысаларында районның муниципаль бюджет мәгариф оешмалары белән күз алдында тотылган бюджет ассигнованиеләре хисабына тормышка ашырыла.

2 нче кушымта

«РАСЛАНГАН»
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
04.09.2019 № 1486

Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы башкарма комитеты
Мәгариф бүлеге" МКУ начальнигы»______
_____________________________________
_______________________________________тан
_________________________________________

_________________ адрес буенча яшәүче
_________________________________________
Тел.______________________________________

Белем алу формасының гаилә мәгарифе
формасын яки үзбелем алу формасын сайлау турында
хәбәрнамә

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елны 29 нчы декабрендәге 63 ст. 5 бүлек таләпләре нигезендә, хәбәр итәм, күрсәтелгән Федераль законның 17 ст. 1 һәм 3 бүлеге, 44 ст. 3 бүлеге 1 һәм 3 пунктлары, 63 ст. 4 бүлеге нигезендә, безнең тарафтан, _______________________________________________ балигъ булмаган баланың әти-әниләре (законл вәкилләре) буларак, аның өчен гомуми белем алу формасының гаилә мәгарифе формасы сайланды. Белем бирү формасын сайлау турында һәм укыту формасы турында карар баланың фикерен истә тотып кабул ителде.

Әлеге хәбәрнамәне алуыгыз турында мине алда күрсәтелгән адреска язма рәвештә хәбәр җибәреп хәбәр итүегезне сорыйм.

Белем бирү формасын сайлау турында һәм укыту формасы турынңа карар баланың фикерен истә тотып кабул ителде.

Дата ______________

Әти-әнинең (законля вәкилнең) имзасы _________________

Баланың имзасы (14 яшьтән соң) _____________________

3 нче кушымта

«РАСЛАНГАН»
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
04.09.2019 №1486

Гражданинның яки аның әти-әниләренең (законлы вәкилләренең) экстерн тарафыннан арадагы һәм/яки дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен мәгариф оешмасына кабул ителүгә гариза формасы

Җитәкчегә___________________________________
(мәгариф оешмасы исеме)
___________________________________________
(мәгариф оешмасы җитәкчесенең фамилиясе, инициаллары)
___________________________________________тан
(фамилия, имя, отчество полностью)
Теркәлү урыны (адрес)
___________________________________________
Законлы вәкилнең статусын раслаучы документ турында мәгълүматлар (№, серия, бирелү вакыты, кем тарафыннан бирелгән)___________________________
Телефон/e-mail ______________________________

Гариза

Мине (минем улымны (кызымны) кабул итүегезне сорыйм_____________________________________________________________________,
(фамилия, исем, этисенең исеме тулысынча)
арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен, ____ класс курсы өчен/ _____________________________ фән (нәр) буенча, гомуми белм алуның бар чорына / арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу чорына / __________________ уку елы чорына.
(кирәклесенең астына сызарга)

Миңа/минем улыма (кызыма) рөхсәт итүегезне сорыйм:
лаборатор һәм практик дәресләргә йөрергә (нинди фәннәр буенча икәнлеген күрсәтергә)_____________________________________________________________;
мониторинг тикшерүләрдә катнашырга _____________________________________________________________________.
(кирәклесенең астына сызарга)

Белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыруга лицензиясе, дәүләт аккредитациясе турында шәһадәтнамә, _____________________________________________________________Уставы,
(мәгариф оешмасының исеме)
мәгариф оешмасының белем бирү программасы, арадагы аттестация уздыру Тәртибе,

Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру тәртибе һәм формалары турындагы Нигезләмә белән таныштым.

Дата __________________ Имза________________

Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә шәхси мәгълүматлар һәм баланың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Дата __________________ Имза ________________

4 нче кушымта

«РАСЛАНГАН»
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
04.09.2019 №1486

БОЕРЫК

"__" ________ 20__ ел ______________________________________ № ______________
(боерыкны төзү урыны)

Экстернны арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау
аттестациясе узу өчен кабул итү турында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 нчы декабрендәге 34 статьясы 3 бүлеге таләпләре нигезендә,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Кабул итәргә_______________________________________________________________
(экстернның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
"__" ______________ 20__ ел дан "__" _______________ 20__ елга кадәр арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен, ____ класс курсы өчен/ ______________________________ фән(нәр) буенча, гомуми белм алуның бар чорына/ арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу чорына/ ____________________ уку елы чорына.

2. Арадагы аттестация уздыруның түбәндәге графигын расларга:

| Фәннәр | Арадагы аттестация уздыру формасы | Арадагы аттестация уздыру сроклары |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

3. Уку фәннәре буенча консультацияләр уздыруның түбәндәге графигын расларга:

| Фәннәр | Консультацияләр уздыру срогы |
|---|---|

| | 1 консультация | 2 консультация |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

4. Укыту-тәрбия эшләре буенча җитәкче урынбасарына__________________________

(урынбасарның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Консультацияләрне уздыруны һәм педагогик хезмәткәрләр тарафыннан арадагы аттестация уздыруны, консультацияләр уздыру исәбе журналын алып баруның үз вакытында икәнлеген контрольдә тотуны тормышка ашыру.

5. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны укыту-тәрбия эшләре буенча җитәкче урынбасарына йөкләргә _______________________________.

(җитәкче урынбасарының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Мәгариф оешмасының җитәкчесе ___________/________________

5 нче кушымта

«РАСЛАНГАН»
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
04.09.2019 №1486

# АРАДАГЫ АТТЕСТАЦИЯ УЗУ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

_______________________________________________________________________________
(фамилия, исем, әтисенең исеме)

_______________________________________________________________________________
(мәгариф оешмасының исеме, адресы)

арадагы аттестация ________________________________ уку елында уздырылган.

| N т/б | Уку фәннәренең исеме | Чирек, триместр, яртыеллык, модуль, сыйныф, фәннең тулы курсы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| 4. | | | |
| 5. | | | |
| 6. | | | |
| 7. | | | |
| 8. | | | |
| 9. | | | |
| 10. | | | |
| 11. | | | |
| 12. | | | |

_________________________ _______________________________ _______ сыйныф.
(укучының Ф.И.О.) (укуын дәвам итә, уздырылган)

Мәгариф оешмасының җитәкчесе ___________/____________________

МУ

"__" ____________ ел

6 нче кушымта

«РАСЛАНГАН»
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
04.09.2019 №1486

Гаилә мәгарифе яки үзбелем алу формасында гомуми
белем алучы укучыга арадагы һәм дәүләт йомгаклау
аттестациясен оештыру һзм уздыру турында
ШАРТНАМӘ

«___ »________________ ел

Гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе «__________________________________________________________________________», алга таба Оешма дип аталучы, Устав нигезендә гамәл кылучы директор йөзендә, бер яктан һәм законлы вәкил (әти-әни, опекун/попечитель), алга таба укучының Вәкиле дип аталучы алга таба Укучы дип аталучы, укучы мәнфәгатьләрендә "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы нигезендә, түбәндәге турында әлеге шартнамәне төзеделә:

**1.** Шартнамәнең предметы:

1.1. Әлеге шартнамәнең предметы булып Укучының арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм уздыру тора.

**2.** Якларның хокуклары һәм йөкләмәләре

2.1. Оешма:

2.1.1. _____________________________________________________________ периодта ___________________________ материаллары буенча стандартлаштырылган формада Укучының арадагы аттестация узуын оештыра һәм уздыра.

2.1.2. Арадагы һәм йомгаклау аттестация нәтиҗәләре нигезендә, законнар белән билгеләнгән тәртиптә Укучыны башка сыйныфка күчерә.

2.1.3.Укучыны аның тарафыннан билгеле программаны алданрак үзләштерү белән бәйле рәвештә билгеләнгән тәртиптә аттестация уздыруны тәэмин итә.

2.1.4. Мәгариф өлкәсендә гамәлдә булган федераль һәм төбәк норматив хокукый актлары нигезендә Укучыга дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыруны тәэмин итә.

2.1.5. Укучы тарафыннан билгеле дәрәҗәдәге гомуми белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләрен үтәгән очракта, аңа дәүләт үрнәгендәге документ (аттестат) тапшыра.

2.1.6. Район мәгариф бүлеген әлеге шартнамә өзелгән очракта, Укучының яшәү урыны буенча мәгариф оешмасында белем алуын дәвам итүе турында мәсьәләне карау өчен хәбәргә куя

2.2. Оешма хокуклы:

2.2.1. Укучыга арадагы аттестация уздыру тәртибен һәм срокларын билгеләргә.

2.2.2. Вәкил тарафыннан чакырылган педагогларның Укучының арадагы һәм йомгаклау аттестациясен уздырганда катнашу мөмкинлеген ачыкларга.

2.2.3. Укучыга тиешле белем турында дәүләт үрнәгендәге документны бирүдән баш тартырга, әгәр дә аның тарафыннан йомгаклау аттестация турында Нигезләмә шартлары үтәлмәгән булса ___________________________.

2.3. Вәкил хокуклы:

2.3.1. Укучы тарафыннан гомуми белем бирү программаларын, Оешма директоры тарафыннан расланган, гаиләдә белем алучы укучыларның арадагы аттестацияләр уздыруның билгеле тәртибе срокларында

2.3.2. Оешма тарафыннан билгеләнгән срокларда Укучының Оешмага килүен тәэмин итәргә, Оешманы Укучының килмәячәге турында аттестация уздырылу вакытына кадәр бер тәүлектән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

2.4. Вәкил аттестация нәтиҗәләре белән танышырга хокуклы.

**3. Якларның җаваплылыгы**

3.1. Оешма Укучыларның арадагы һәм (яки) дәхләт йомгаклау аттестациясен уздыру сыйфаты өчен җаваплылык йөртә.

3.2. Вәкил Укучының дәрәҗәдәге гомуми белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартлары кысаларында, гомуми белем бирү программаларын үзләштерүе өчен җаваплылык йөртә.

**4. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы**

Әлеге шартнамә яклар тарафыннан аны имзалагач үз көченә керә һәм ________________________ елга кадәр гамәлдә була.

**5. Шартнамәне өзү тәртибе**

5.1. Әлеге шартнамә өзелә:

5.1.1. Оешма бетерелгәндә.

Әлеге шартнамә буенча йөкләмәләр Оешманың хокуклы варисына күчми.

Вәкил хокуклы взкил белән билгеләнгән тәртиптә яңа шартнамә төзи.

5.1.2. Укучы тарафыннан гариза буенча гомуми белем алу формасы үзгәргән очракта.

5.1.3. Арадагы һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре белән Укучы тарафыннан гомуми белем бирү программаларын үзләштерелмәве расланган очракта.

5.2. Әлеге шартнамә бер яклы тәртиптә өзелә:

5.2.1. Оешма тарафыннан әгәр дә Вәкил әлеге шартнамә буенча йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта.

5.2.2. Вәкил тарафыннан аның теләге буенча, Ошема җитәкчесе исеменә гариза рәвешендә рәсмиләштереп.

**6. Йомгаклау өлеше**

6.1. Әлеге шартнамә 2 нөсхәдә һәр ике як өчен төзелгән. Ике нөсхә дә бердәй юридик көчкә ия. Бер нөсхә оешмада саклана, икенчесе –Вәкилдә.

**7. Якларның реквизитлары һәм имзалары**

7 нче кушымта

«РАСЛАНГАН»
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
04.09.2019 №1486

Гаилә мәгарифе һәм үзбелем алу формасында белем алучы балаларның исәбен алу журналы

| № | Баланың ФИО/туган вакыты/сыйныф | Яшәү урыны /телефон | Әти-әни (законлы вәкил)/гаризаны тапшыру вакыты | ББУ исеме (арадагы яки дәүләт йомгаклау аттестациясенә) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |